ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АКТАНЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 3 маендагы 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Актаныш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү, аларның хезмәте өчен түләүне камилләштерү һәм һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата хезмәт хакы турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы контроль-хисап органнары рәисләре, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр, Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 22 мартындагы ПУ-239 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» Актаныш муниципаль районы 03.05 2018 № 6 карары нигезендә, 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Әлеге карар “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы” нда басылып чыкканнан соң үз көченә керә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Актаныш авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.”.

2. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмати порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегенең рәсми сайтында әлеге карарны бастырып чыгарырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет рәисе,
авыл җирлеге башлыгы Э.Н. Фәттахов